ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 30 июле** **Чистай шәһәре** **№ 395**

2020 елның III кварталына
Чистай муниципаль районы буенча
торакның 1 квадрат метр гомуми
мәйданының уртача базар бәясе турында

Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2020 елның 29 июнендәге 351/пр номерлы “2020 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының нормативы һәм 2020 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында” гы Боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарның барлык категорияләренә дә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, 2020 елның III кварталына Чистай муниципаль районы буенча торакның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен (сумнарда) 53 024 (илле өч мең егерме дүрт) сум күләмендә расларга, аларга күрсәтелгән социаль түләүләр федераль бюджет акчасы хисабына торак бина сатып алу (төзү) өчен бирелә.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары П. Б.Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов